Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге составына керүче
Ташкичү торак пунктында 2020ел ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ
турында

2020 елның 10 ноябере № 4

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 10 ноябрендә узган граждannар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Ташкичү торак пунктының Чишмә урамының юл-урам челтәрен ремонтлау».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 114 граждан кертелгән, 61 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 53,5% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 61 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү торак пунктында халык җыенын узган дип санарга, халык җыенының нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

   - Ташкичү торак пунктының Чишмә урамының юл-урам челтәрен ремонтлау" - соравы буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм www.yutaza.tatar.ru электрон адресы буенча Ютазы муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар халыкка рәсми игълан иткән көннән үз көченә керә.

Җыенда рәислек итүче Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Вәлиев